**3. Кабатлау, ныгыту.**

- Яхшы! Хәзер телдән кабатлауга күчәбез. Санга нинди билгеләмә бирдегез?

- Язуда нинди саннар кулланабыз?

- Ясалышы буенча саннар нинди була?

- Исемләшкән саннар турында нәрсә әйтә аласыз?

**Физкультминут**

- Ә хәзер укучылар бераз ял итеп алабыз. *МИКС – ФРИЗ – ГРУП* структурасын кулланырбыз. Укучылар, без хәзер барыбыз да бер әйләнә ясап басабыз. Музыка кушыла, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, сез бер урында басып каласыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез шул сорауның җавабын миңа укучылар саны ярдәмендә күрсәтергә тиеш буласыз.

1. Татар телендә ничә килеш бар? (6)
2. Сыйфатларның ничә дәрәҗәсен беләсез? (4)
3. Сан сүзендә ничә тартык? (2)
4. Санның ничә төркечәсе бар? (5)

- Нинди төркемчәләрне беләсез? Саннарның төркемчәләргә аера белүегезне КОНЭРС структурасын кулланып тикшерербез. Мин сезгә төрле төркемчәдәге саннар язылган карточкалар өләшәм. Саннарыгыз нинди төркемчәгә туры килә, шул почмакка басасыз. Бер-берегезгә сүзләрне укыйсыз, тикшерәсез һәм шул төркемчә турында сөйләргә өйрәнәсез. 2 минут вакытыгыз бар.

- Тикшерәбез.

Тәртип саны. Укыйбыз. Тәртип саннарын кайчан кулланабыз?

Җыю саны. Укыйбыз. Нинди кушымчалары бар?

Чама саны. Укыйбыз. Ничек ясала?

Бүлем саны. Укыйбыз. Нинди үзенчәлеге бар?

- Рәхмәт, утырдык. Ә хәзер игътибар белән тыңлыйсыз. Мине барыгыз да ишетәсезме? (Кулны күтәрәм. Укучылар да яза торган кулларын күтәреп җавап бирәләр.) Өйгә эш, саннар белән җөмләләр төзү булачак. Ә нинди саннар икәнен без ДЖОТ ТОТС структурасы ярдәмендә беләчәкбез. 2нче номерлы укучы 4әр бит өләшә. Берәр сан язасыз, укыйсыз, уртага куясыз. Аннары 1нче номер сүзләрне сайлап ТИК-ТЭК-ТОУ структурасы буенча эшләргә әзерли. Сез саннарны дәфтәргә күчерәсез, ә җөмләләрне инде өйдә төзисез. Сүзләрне я диогональ, я вертикаль, я горизонталь буенча алырга кирәклеген онытмыйбыз. Сезгә 3 минут вакыт бирелә.

